ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Сәрдек авылы торак пунктында

2019 елның 30 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сәрдек авылында гражданнар җыены карар итте:

1. 2020 елда Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 18 яшькә җиткән, 1 нче төркем инвалидларыннан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контракт хезмәте үтүче хәрби хезмәткә алынучылардан (алар өчен үзара салым суммасының 90% ы күләмендә ташлама билгеләнгән) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Су алу җайланмасы төзелешенә проект-смета документациясен эшләү ;
- Артезиан скважинасы өчен су астына төшә торган насос сатып алу;
- Тынычлык урамындагы юлны ремонтлау.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (<url>) гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә .http://pravo.tatarstan.ru Балтач муниципаль районы сайтында http:// baltasi.tatar.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев